КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 июль г.Казань № 590

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренә аларны төзегәндә устав фондын формалаштыруга һәм устав фондын арттыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 28 декабрь, 1024 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренә аларны төзегәндә устав фондын формалаштыруга һәм устав фондын арттыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренә аларны төзегәндә устав фондын формалаштыруга һәм устав фондын арттыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 28 декабрь, 1024 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 29 декабрь, 1108 нче; 2018 ел, 1 июнь, 416 нчы; 2018 ел, 5 сентябрь, 754 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренә аларны төзегәндә устав фондын формалаштыруга һәм устав фондын арттыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«яңа эш станцияләре, серверлар, компьютерлар сатып алуга, капиталь төзелеш өлкәсендәге республика программаларын мәгълүмат технологияләрен кертү юлы белән тормышка ашыруны тәэмин итә торган проектлаштыру һәм инженерлык эзләнүләре эшләрен камилләштерү өчен программа продуктларын куллануга лицензияне яңартуга һәм озайтуга.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин